Казан шәһәре Вахитов районы 12 нче татар телендә белем бирүче гимназия

# АННОТАЦИЯ, ОТЗЫВ, РЕЦЕНЗИЯ- ФӘННИ СОЧИНЕНИЕ ЯЗУ НИГЕЗЛӘРЕ

## (ТАТАР ӘДӘБИЯТЫННАН ЭЛЕКТИВ КУРС ПРОГРАММАСЫ)

**ТӨЗЕДЕ: ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУЧЫСЫ НАСЫЙБУЛЛИНА ГӨЛНУР ЗӘКӘРИЯ КЫЗЫ**
**РЕЦЕНЗИЯ БИРҮЧЕ: КДППУның татар теле һәм әдәбияты доценты Гәрәева Гөлүсә Фәрит кызы**

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Китап- ул кешенең уйларын чагылдыра
торган сирәк могҗизаларның берсе.
И. Гази

Китап кешене галәмнең хуҗасы итә.
П.А. Павленко

Хәзерге заманда кешенең рухи дөньясы, фикерли белүе, заман таләп иткәнчә беренче планга чыга барганлыктан, һәр мәктәп , һәр укытучы үз йөзен булдырырга; мөстәкыйль, иҗади, әхлак ягыннан сау-сәламәт, камил шәхес тәрбияләргә тырыша. Шуңа күрә үз фикереңне эзлекле рәвештә әйтә белү, фикереңне дәлилләп бәхәстә катнаша алу - кирәкле сыйфатларның берсе булып санала.

Балада бу сыйфатларны тәрбияләүдә, һичшиксез, матур әдәбият әсәрләренең роле зур. Сер түгел, компьютор технологиясе, интернет челтәре бала күңелен яулаганнан яулый бара. Укучыларыбызның күбесе бүген әдәби әсәрләр уку белән мавыкмый диярлек. Китап кибетләренә, китапханәләргә бик сирәк керә. Андагы китаплар белән бөтенләй кызыксынмый я булмаса укытучы таләп иткәнгә күрә генә аларга күз сала. Менә шундый шартларда ничек итеп укучыны китап дөньясына алып керергә? Сүзнең нинди илаһи көчкә ия булуын балага ничек төшендерергә? Шуның белән бергә фән дөньясына ничек итеп юл салырга?

Бу проблемаларны хәл итү өчен безгә, иң беренче чиратта, матур әдәбият әсәрләрен укуны баланың көндәлек хаҗәтенә әйләндерерлек итеп , укучыда китапка карата кызыксыну, мавыгу уятырга кирәк. Әлбәттә, укылган әсәрләр бала күңелендә йомылып калырга тиеш түгел. Ул алар турында кемгә булса да сөйләргә, тәэсирләре белән уртаклашырга, уку барышында туган уй-фикерләрен яклый, дәлилли белергә тиеш. Укучыда мондый күнекмәләрне булдыру өчен мин әсәргә аннотация, отзыв, бәяләмә язарга өйрәнү бик зарур дип саныйм. Сочинениенең бу жанрларын язарга өйрәтергә генә түгел, укучыны шуңа күнектерегә дә кирәк.

Әгәр дә мәктәп программаларына һәм методик кулланмаларга күз салсак, бүгенге көнгә кадәр бу өч төшенчә турында кирәкле тулы мәгълүмат һәм эш системасы юклыгын күрербез. Ә бит укылган китапка яки әсәргә аннотация, отзыв, бәяләмә сочинениеләрнең нигезен тәшкил итә һәм фән белән бик тыгыз бәйләнештә тора. Ә дәресләрне фән белән бәйләп алып бару- хәзерге заман таләбе.

Татар мәктәпләренең 9 нчы сыйныфы программасында сочинение жанрлары турында (монография, мәкалә, очерк, хат, рецензия, аннотация һ. б.) тулы белешмә бирүгә 2 сәгать бүленеп бирелә. Ләкин ул бары тик гомуми планда гына карала. Бу жанрлар өстендә эшләү, чын асылын ачып бирү, аларны язарга

күнектерү өчен программада күрсәтелгән ана теле дәресләре генә җитми. Шуны да онытмаска кирәк, татар теле һәм әдәбият укытучысының изге бурычына үз укучыларын яңа чыккан әдәби әсәрләр белән даими таныштырып бару да керә.

Электив курс нәкъ менә шушы проблемаларны күз алдында тотып язылды да инде. Бу программаны кулына алган кеше, тел һәм әдәбият дәресләрендә сочинение жанрының өч төрен язарга өйрәткәндә, кирәкле материалга ия булыр дигән фикердә калам.

Электив курс 10 класс укучылыры өчен төзелде.

17 сәгатькә исәпләнелде.

## ПРОГРАММАНЫҢ МАКСАТЫ:

1. Укыган китапка яки әсәргә аннотация, отзыв, бәяләмәгә булган таләпләр белән таныштыру, аларның үзенчәлекләрен ачу.
2. Әдәбият дәресендә алган белемнәренә һәм класстан тыш укылган китапларына таянып, дөрес итеп аннотация, отзыв һәм бәяләмә язарга өйрәтү, күнектерү.
3. Образлы һәм фәнни фикерләү сәләтләрен үстерү.
4. Укучыларда мәгълүматлылык булдыру.

## ПРОГРАММАНЫҢ БУРЫЧЛАРЫ:

1. Дөньяны һәм үз-үзеңне танып–белү өчен матур әдәбият әсәрләрен укуга ихтыяҗ тудыру.
2. Төрле дәрәҗәдәге катлаулы әдәби әсәрләрне төптән аңларга һәм анализларга өйрәтү.
3. Мөстәкыйль рәвештә китап уку аша әдәбият фәнен үзләштерү.
4. Матур әдәбият әсәрләре ярдәмендә укучының иҗади фикерләү сәләтен, бәйләнешле сөйләм телен үстерү, мөстәкыйльлек тәрбияләү.
5. Әдәбият, язучылар, аларның әсәрләре турындагы белемнәрен системага салу.
6. Грамоталы һәм компетентлы шәхес тәрбияләү.

Дәрестә кулланылган технологияләр:

- эзләнү-тикшеренү технологиясе;
- проблемалы укыту технологиясе;
- мәгълүмат бирү технологиясе.

Дәрес төрләре: дәрес-лекция, репродуктив дәрес, проблемалы дәрес, дәрес-диспут, укучылар конференциясе, дәрес-презентация, дәрес-экскурсия

## УКЫТУ- ТЕМАТИК ПЛАН

| № | Тема | Сәгать саны | Эш төре |
|---|---|---|---|
| 1. | Китап уку –иң яхшы белем алу. | 1 | Әңгәмә,фикер алышу |
| 2. | “Мәгариф” нәшрияты китап кибетенә сәяхәт | 1 | Күзәтү, әңгәмә |
| 3. | Сочинение жанрлары турында | 2 | Лекция. әңгәмә |
| 4. | Аннотация-китап сайларга ярдәм итә | 1 | Уку, әңгәмә |
| 5. | Аннотация язу серләре | 1 | Уку, әңгәмә |
| 6. | Иң яхшы аннотацияләр презен-тациясе | 1 | Уку, фикер алышу, дискуссия |
| 7. | Отзыв (фикер әйтү) һәм аның билгеләре | 1 | Әңгәмә, эзләнү- тикшеренү |
| 8. | Отзывлар дөнясында | 1 | Әңгәмә, фикер алышу |
| 9. | Практик дәрес. Отзывлар язу, аларны камилләштерү | 1 | Фикер алышу,эзләнү-тикшеренү |
| 10. | Практик дәрес. Отзывлар проекты | 1 | Фикер алышу |
| 11. | Бәяләмә язу алымнары | 1 | Уку, әңгәмә. |
| 12. | Отзыв һәм бәяләмә композициясендә аермалыклар | 1 | Эзләнү- тикшеренү |
| 13. | Бәяләмә язу һәм аларны редакцияләү | 1 | Уку, сорауларга җавап бирү |
| 14. | М. Маликова белән очрашу | 1 | Әңгәмә, фикер алышу |
| 15. | Дәрес- зачет | 1 | Тест сорауларына җавап бирү |
| 16. | Йомгаклау конференциясе | 1 | Уку, әңгәмә, бәхәсләшү |
| 17. | “Мәгариф” нәшрияты китап кибетенә бару. Яңа китап тәкъ-дир итүдә катнашу | 1 | Экскурсия, фикер алышу |

## КУРСНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

1. Китап һәм аның кеше тормышында тоткан урыны турында әңгәмә.

Китап басу эше турында мәгълүмат. Китап турында халык мәкальләре,

фикер ияләренең канатлы гыйбарәләре.

Китап укуның ләззәте турында Г. Тукайның “Китап” шигырендә.

2. Бауман урамында урнашкан “Мәгариф” нәшрияты китап кибетенә экскурсия. Укытучы классик язучыларыбызның әсәрләре, яшъ язучыларыбызның китаплары турында мәгълүмат бирүне шушында эшләүче хезмәткәрләр белән оештыра. Очрашу сорау -җавап рәвешендә үтә.
3. Сочиннение жанрлары.Сочинение төрләре булган сочинение- хөкем йөртү, сочинение- сурәтләү, сочинение- хикәяләү искә төшерелә, үрнәк сочинениеләр укыла, эчтәлекләре буенча әңгәмә уздырыла, белемнәре тирәнәйтелә. Публицистик стильгә караган сочинение жанрларыннан репортаж, очерк, эссе, отзыв, рецензия кебек жанрлар турында сөйләнелә. Мисаллар өстендә аңлатыла.
4. Аннотация турында аңлатма бирелә һәм аны язу максаты әйтелә. М. Әмирхановның “ И кылган догам минем”, М. Маликованың “Кызыл гөл” китапларына, Ф. Яхинның “Маржа яме” хикәясенә язылган аннотацияләр белән танышып үтү, фикер алышу.
5. Аннотация язу үзенчәлекләренә тукталу. Укучыларга аннотация язу алгоритмнарын тәкъдим итү. Үзләре укып чыккан әсәрләргә аннотация язарга тәкъдим итү.
6. Дәрес-презентациядә укучылар өйдә язып килгән аннотацияләрен укыйлар. Аны яклыйлар, сорауларга җаваплар бирәләр.Үзбәя, үзара бәя, укытучы бәясе аша иң камил эшләр сайланып алына, гимназия сайтына урнаштырыла.
7. Отзыв турында аңлатма искә төшерелә. Аны язуның максаты аңлатыла. Ә. Еникинең “Матурлык” хикәясенә язылган отзыв аша аны язу үзенчәлекләре китерелеп чыгарыла.
8. Яңа чыккан китапларга отзывлар укыла, аларның эчтәлеге буенча фикер алышына.Шуның нәтиҗәсендә укучыларны кызыксындырган китаплар исемлеге төзелә.
9. Практик дәрес. Ф. Бәйрәмованың “Караболак” әсәренә укытучы ярдәмендә отзыв язу, аны камилләштерү.
10. Практик дәрес. Отзывларга язылган проектлар турында фикер алышу, камилләштерү. Иң уңышлы эшне гимназия сайтына урнаштыру.
11. Бәяләмә турында аңлатма искә төшерелә. Китапларга язылган Бәяләмәләр укыла. Эчтәлекләре буенча фикер алышына. Аны язу

алымнары билгеләнелә.

12. Бәяләмә һәм отзыв композициясендәге аермаларны билгеләү.
    М. Маликованың “Кызыл гөл” китабындагы әсәрләргә бәяләмәләр язу.
13. Бәяләмәләрне редакцияләү, камилләштерү. Уңышлы эшләрне үзбәя, үзара бәя, укытучы бәясе аша билгеләү.
14. М. Маликова белән очрашу. Укучылар кызыксындырган сорауларга җавап бирү. Аның әсәрләренә язылган презентацияләр белән таныштыру, фикер алышу.
15. Дәрес-зачетта укучыларның электив курс буенча тупланган теоретик һәм практик белемнәрен барлау.
16. Китап укучыларның йомгаклау конференциясе. Иң яхшы иҗади эшләр күргәзмәсе.
17. ”Мәгариф” нәшрияты кибетендә үткәрелгән яңа чыккан китап тәкъдир итү кичәсендә катнашу, үз фикерләрең белән уртаклашу.

# КУШЫМТА

# АННОТАЦИЯ

Үзебезгә кулай дип табылган китапны ничек сайларга?
Бу сорауга җавапны без электив курсның “Аннотация һәм аны язу серләре” дигән бүлегеннән таба алырбыз. Аннотация бер әсәрнең икенчесеннән нәрсә белән аерылып торуы яки өстенлекләре турында үз укучыларына мәгълүмат бирә, анда кайсы төркем укучылар өчен язылуы да әйтелеп кителә. Аннотация укучыга үзе укырга теләгән китабын сайлап алырга мөмкинчелек тудыра. Шулай ук текст алдыннан я булмаса ахырында әсәрнең авторы, исеме, басылу урыны һәм вакыты турында да мәгълүмат урнаштырыла.

Электив курс, үрнәк максатыннан, яңа чыккан китапларга язылган аннотацияләр укуны, алар буенча фикер алышуны да күз алдында тота. Мәсәлән, М. Әмирхановның “ И кылган догам минем”, М. Маликованың “Кызыл гөл” китапларына, Р.Сибатның “ Кайту” трилогиясенә, Ф. Яхинның “Марҗа яме” хикәяләренә язылган аннотацияләр белән танышып үтәргә мөмкин. Шулай ук укучыларга аннотация язу алгоритмнары тәкъдим ителә.

Китапта нәрсә (кем) турында сөйләнелә?
Нәрсә (кем) күрсәтелгән?
Нәрсәне карау зур урын алып тора?

Автор нәрсәгә таянып фикер йөртә?
Нәрсәне билгеләп үтә?
Нәрсәне ассызыклый?

Китапта нәрсә бирелә?
Нәрсә ачыла?
Нәрсә сурәтләнә?

Монографиядә нәрсәгә характеристика бирелә?
Сорауга нинди проблемаларны чишү аша җавап бирелә?

Алгортмнар буенча үзләре укыган берәр китапка аннотация язу һәм аларны камилләштерү. Презентация төзү. Үзбәя, үзара бәя, укытучы бәясе аша иң яхшы эшләрне билгеләп үтү/

## ОТЗЫВ (ФИКЕР ӘЙТҮ)

Укыган китап яки әсәрдән соң туган фикерләрне, тәэсирләрне башкаларга җиткерү, шул рәвешле аерым бер сәнгать төренә яки әдәби әсәргә китап укучылар игътибарын юнәлтү, кызыксындыру уяту отзыв язуның максаты булып тора. Отзыв эчтәлеге безгә әдәби әсәргә хас булган сыйфатларны түгел, ә бәлки, авторның текстта чагылган тормыш вакыйгаларына, анда катнашкан персонажларга карата туган фикерләрен, карашын ачып бирә. Шуңа күрә анда авторның шәхси хисләренә караган элементлар төп урын алып тора. Эчтәлеге мондый булырга мөмкин: укыдым-гаҗәпләндем-уйландым.

Отзыв эчтәлеген ачу өчен түбәндәге сораулардан файдалану да укучыга ярдәм итәр:

-укыган китап сездә нинди тәэсир калдырды (кызыксыну, мавыгу, дулкынлану хисләре)?

-мондый фикергә килүнең сәбәбен аңлатыгыз (сюжет сызыгы, персонажлар, аларның үз-үзен тотышы, теманың актуальлеге һ. б. );

- әсәрне укымаган кешеләр өчен аңларлык итеп кыскача сюжет сызыгы белән таныштырыгыз;

-авторның үз геройларының тышкы кыяфәтен, эчке дөньяларын сурәтләү алымы сезгә ошадымы ? Сез алар кебек яшәр идегезме?

- вакыйгалар һәм табигать күренешләрен сурәтләү үзенчәлегенә игътибар итегез. Аларның әдәби әсәрдә тоткан роле турында фикерләрегез белән уртаклашыгыз;

-китапның язу стиленә, теленә игътибар итегез. Әсәрнең асылын ачуда аларның ролен билгеләгез;

-сезгә бу китап авторы танышмы, аның тагын нинди әсәрләрен укыганыгыз бар?

-ул башка язучылардан кайсы ягы белән аерыла? Аның әсәрләре сине кайсы яктан үзенә җәлеп итә?

-укыган китап тормыштагы нинди дә булса яңалыкны ачарга ярдәм иттеме?

Шул ук вакытта отзыв жанрының - мөстәкыйль жанр булуы һәм шул сәбәпле аны нинди дер кысалар эченә кертеп язу мөмкин эш түгел икәнлеге искәртелә.

М. Маликованың “Кызыл гөл” китабына отзывлар языла. Алар дәрестә укыла, фикер алышу төркемнәрдә тикшерелә.

## РЕЦЕНЗИЯ (БӘЯЛӘМӘ)

Рецензия- китапка яисә әдәби әсәргә бәя бирү яки аны тәнкыйть итү дигән сүз. Аның нигезендә укыган әсәргә анализ ясау, язучының стиленә, сәнгатьчә сурәтләү чараларына, әсәр композициясенә, образлар системасына бәя бирү ята. Шуны да онытмаска кирәк: укучыны аннотация, отзыв язарга өйрәтү - ул укучыны рецензия язарга өйрәтүнең башлангыч һәм хәзерлек этабы булып тора. Рецензия язучы һәр фикерен әсәрдән алган мисаллар ярдәмендә дәлилли. Сочинение –рецензиянең төзелеше түбәндәгечә дә булырга мөмикин: бәя - аны ачу- дәлилләү.

**Рецензия -сочинение язу өчен ярдәмлек.**

Китап сезнең тарафтан ничек укылды? Башка укучылар тарафыннан ничек кабул ителәчәк?

Әсәрнең темасын, төп фикерен, проблемасын билгеләгез. Язучы безне нәрсәгә инандыра? Ул моңа ничек ирешә? ( Мисаллар ярдәмендә дәлилләгез) .

Китап геройлары кемнәр? Алар нәрсә белән шөгыльләнә? Холыклары, тормыштагы максатлары, омтылышлары турында сөйләгез. Авторның геройларны сурәтләү осталы ни дәрәҗәдә? (Дәлилләгез.)

Композиция үзенчәлекләре турында нәрсә әйтә аласыз?

Сурәтләү чараларының әсәр төзелешендә тоткан урынын билгеләгез.

Әсәр нинди тел белән язылган? Ул автор әйтергә теләгән фикерләрне төгәл ачарга ярдәм итәме?

Китапка сезнең гомуми карашыгыз. Бу әсәр, сезнеңчә, әдәбиятка нинди яңалык алып килде? Сезнеңчә, нәрсәгә аеруча игътибар итәргә кирәк? Уңышсыз ягы дип нәрсәне саныйсыз?

Әсәрнең исеме китапның эчтәлегн ачамы?

Әсәр тудырган тәэсирләр.

Җаваплар сезнең рецензиягезнең нигезен тәшкил итәчәк.

**Аннотация, отзыв, рецензия**

Схема

| аннотация | отзыв | рецензия |
|---|---|---|
| Укучы өчен информация<br><br>Нәрсә турында? | Әсәргә фикер әйтү характерында<br>Миңа ничек тәэсир итте? Ни өчен? | Бәяләү + анализ<br>(Минем мөнә- сәбәтем) (Әдәби-тео- ретик харак- терда) |

**Аннотация язу үрнәге**

Яхин Фәрит Зәкиҗанович
МАРҖА ЯМЕ
Кече жанр -чәчмә әсәрләр

Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2005

Бу җыентыкка язучының узган гасырның соңгы елларында, яңа меңьеллыкның тәүге елларында иҗат ителгән хикәяләре, хикәят, эссе һәм нәсерләре кертелде. Алар китап буларак бергә тупланып беренче тапкыр бастырылып чыгарылалар. Әсәрләрендә автор татар тормышы хакындагы уйлануларын һәм дөньялык барышын күңелләргә хуш килерлек дәрәҗәдә тасвир итә. Аның китаплары укучыларны бервакытта да битараф калдырмадылар, каләменең матур һәм тәэсирле тибрәшле булуы күпләрне үзенә тартып тора.

**Рецензия үрнәге**

Мин әйттем: Татар язучыларының афоризмнары, хикмәтле сүзләре, фәлсәфи уйланулары
Төзүчеләре: ГӘ.Нәбиуллина, Л.Г. Гыйләҗева
Казан: "Мәгариф" нәшрияты 2008

Татар халкының гасырлар буена тупланып килгән хикмәтле сүзләре, мәкаль һәм әйтемнәр рәвешендә сакланып, буыннан-буынга, телдән-телгә күчеп, шомарып, безнең көннәргә килеп җиткән. Язма әдәбият барлыкка килгәннән соң, акыл ияләренең тирән мәгънәле фикерләре ядкарь-истәлекләрдә теркәлә башлый. Борынгы төрки рун язмаларында (VI—VII гасырлар), Й.Баласагунлының "Котадгу белег" поэмасында (1069—1070) һәм М.Кашгарыйның "Диване лөгатет-төрк" сүзлегендә (1072—1074) афористик гыйбарәләрнең булуы мәгълүм. Шулай ук урта гасырларда яшәп иҗат иткән күренекле шәхесләребез әсәрләрендә татар халкының акыл-зирәклеген, тормыш һәм яшәү тәҗрибәсен, фәлсәфи карашларын, белем-хикмәтен, тел һәм иҗат байлыгын чагылдырган хикмәтле сүзләрнең матур үрнәкләрен очратырга мөмкин.

Тирән һәм үткен фикерне җыйнак, сурәтле итеп әйткән афористик иҗатны эченә алган әлеге җыентык сүз сәнгате хәзинәсен барлау, туплау һәм бүгенге, киләчәк буыннарга җиткерү максатыннан чыгып төзелгән. Чыганак итеп борынгы гомумтөрки ядкарьләр, урта гасырлардан алып хәзерге чоргача дәвердә иҗат иткән язучы-шагыйрьләрнең (барлыгы 200гә якын) әдәби әсәрләре файдаланылган. Билгеле, әдәби хәзинәбезне, бигрәк тә соңгы елларда басылган китапларны тулаем барлап чыгу мөмкин булмау сәбәпле, бу эш алдагы басмаларга чагылыр дигән теләктә калам.

Китап 30 тематик бүлектән тора. Аларда ил, халык, сәясәт, дин-йола, тел-сүз кебек гомуми иҗтимагый мәсьәләләр белән бергә тормыш, гаилә, хатын-кыз һәм ир-ат, әхлакый кыйммәтләр, мәхәббәт, бәхет, изгелек, гыйлем, дуслык һәм башка шундый мәңгелек төшенчәләр яктыртыла.

Афористик гыйбарәләрне урнаштыруда, авторларның яшәү һәм иҗат итү елларына бәйле рәвештә, хронологик эзлеклелекне сакларга тырыштык. Материалны шундый тәртиптә бирү вакыт агышын тоярга, татар халкының гасырлар дәвамында формалашкан иҗтимагый-фәлсәфи фикер тарихын, әхлакый-этник кануннарын, дөньяга карашын, яшәеш кыйммәтләренә мөнәсәбәтен үсештә-үзгәрештә күзалларга мөмкинлек тудыра.

Укучы әлеге китапта фикер җәүһәрләрен — акыллы һәм тирән мәгънәле фәлсәфи уйланулар, канатлы сүзләр, хикмәтле шигъри юллар һәм юмор белән сугарылган «төрткеләр» табар.

Китап киң катлау укучыларга -укытучыларга, журналистларга, студентларга, гомумән, әдәбият яратучыларга, фәлсәфә һәм сүз сәнгате белән кызыксынучыларга кызыклы һәм файдалы булыр дип ышана.

## КӨТЕЛГӘН НӘТИҖӘЛӘР

Курста алган белемнәре һәм күнекмәләре нәтиҗәсендә укучылар түбәндәгеләргә ия булалар:

· әдәби әсәрләргә фәнни яктан якын килергә;
· автор текстын анализлый белергә һәм аңа тәнкыйть күзлегеннән карарга;
· төрле мәгълүмат чыганакларын чагыштырып карарга һәм үзеңнең нәтиҗәңне ясарга;
· проектлар презентациясен телдән һәм язмача төзү технологиясенә;
·конференцияләр, дискуссияләр үткәрү тәҗрибәсенә ;

Курс ахырында укучылар эшеннән торган күргәзмә оештырыла, йомгаклау конференциясе үткәрелә.

## УКУЧЫЛАР ЭШЕНӘ БӘЯ БИРҮ

Укучы укытучы тарафыннан тәкъдим ителгән ике эш төрен тапшырган очракта аңа зачет куела.

Таләпләр:
-текстның дәлилле, нигезле һәм оригинальлеге;
-язучы әсәрен кӧтелмәгән башка әсәрләр белән чагыштыру;
-бер яки берничә текстка рецензия язу

Курсны өйрәнү барышында дәресләргә иҗади, мөстәкыйль әзерләнгән һәм кызыксынып эшләгән укучыларга яңа чыккан китаплар бүләк ителә, театрга билетлар бирелә.

\

# ФАЙДАЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ


1. Ахманова О.С. Словарь лингвистических терминов. М.: Советская энциклопедия, 1969.
2. Богданова Г.А. Отзыв и рецензия (Материалы к факультативному курсу «Теория и практика сочинений разных жанров») // Русский язык в школе 1985. №4. С. 29-34.
3. Богданова Г.А. Отзыв о самостоятельно прочитанном художественном произведении как вид ученического сочинения // Русский язык в школе.1984. №1. С. 32-37.
4. Калганова Т.А. Выпускное сочинение в 11 классе // Литература в школе. 1995. № 2.
5. Каюмова Г. Ф. Татар теле һәм әдәбиятын укыту тәҗрибәсеннән.- Казан,2003.-28 б.
6. Котельникова С.А. Аннотация — отзыв — рецензия — эссе // Русский язык в школе. 1998. № 1. С. 12-18.
7. Никитина Е. И. Русская речь для 8- 9 классов. -Москва, 1995. -191 стр.
8. Рифә Рахман-Казан, 2004.-2-7 б.
9. Татар урта гомуми белем мәктәпләре өчен татар теленнән программа.- Казан, 2003.-22--29 б.-191 стр.
10. Хәбибуллина З. Н., Миңнуллина Р. В. Сочинение язарга өйрәнәбез.- Казан,2002.-35-45 б.
11. Штильман С. Еще раз про рецензию // Я иду на урок литературы. Готовимся к экзаменационному сочинению. 11 класс. М.: 2001. С. 159-167.